КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 апрель г.Казань № 214

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 17 июнь, 443 нче карары белән расланган 2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 ел, 17 июнь, 443 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июнь, 559 нчы; 2023 ел, 22 июнь, 736 нчы; 2023 ел, 19 октябрь, 1325 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тәрбия - шәхесне үстерүгә, укучыларда хезмәт сөючәнлекне, хезмәткә һәм аның нәтиҗәләренә җаваплы мөнәсәбәтләрне формалаштыруга, социомәдәни, традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләре һәм Россия җәмгыятендә кабул ителгән кеше, гаилә, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә үз-үзен билгеләү һәм социальләштерү өчен шартлар тудыруга, укучыларда ватанпәрвәрлек, гражданлык, Ватанны саклаучылар истәлегенә һәм Ватан Геройлары батырлыкларына хөрмәт, законга һәм хокук тәртибенщ, хезмәт кешесенә һәм өлкән буынга хөрмәт, үзара ихтирам, Россия Федерациясенең күпмилләтле халкы мәдәни мирасына һәм традицияләренә, табигатькә һәм әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тәрбия сыйфаты- шәхесне үстерүгә, укучыларда хезмәт сөючәнлекне, хезмәткә һәм аның нәтиҗәләренә җаваплы мөнәсәбәтләрне формалаштыруга, социомәдәни, традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләре һәм Россия җәмгыятендә кабул ителгән кеше, гаилә, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә үз-үзен билгеләү һәм социальләштерү өчен шартлар тудыруга, укучыларда ватанпәрвәрлек, гражданлык, Ватанны саклаучылар истәлегенә һәм Ватан Геройлары батырлыкларына хөрмәт, законга һәм хокук тәртибенщ, хезмәт кешесенә һәм өлкән буынга хөрмәт, үзара ихтирам, Россия Федерациясенең күпмилләтле халкы мәдәни мирасына һәм традицияләренә, табигатькә һәм әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәт формалаштыруга йөз тоткан тәрбия процессының нәтиҗәләренә интеграль характеристика»;

7 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин